Ә.Н. Хуҗиәхмәтов, И.Ф. Яруллин

# ТӘРБИЯ ТӘГЪЛИМАТЫ
## буенча
## лекцияләр курсы



УДК 37.0
ББК 74.200 (2 Рос = Тат)
Х 98

**Рецензентлар:**

***Р.Х. Хәйруллин*** – педагогика фәннәре докторы, Мәскәү дәүләт педагогика университеты профессоры;

***В.Г. Закирова*** – педагогика фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, кафедра мөдире;

***Җ.Н. Мотыйгуллин*** – педагогика фәннәре кандидаты, доцент, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының бүлек җитәкчесе.

*Охраняется Законом РФ «Об авторском и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хуҗиәхмәтов Ә.Н.**

**Х 98** Тәрбия тәгълиматы буенча лекцияләр курсы: Югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку әсбабы / Ә.Н. Хуҗиәхмәтов, И.Ф. Яруллин. – Казан: ТРН «Мәктәп», 2016. – 256 б.

**ISBN 978-5-7761-58-6**

© Хуҗиәхмәтов Ә.Н., Яруллин И.Ф., 2016
©ТРН «Мәктәп», 2016

***Беренче лекция***

## ТӘРБИЯ ЭШЕНЕҢ ФОРМАЛАРЫ

Педагогика фәнендә тәрбия эшенең формасы турында бердәм фикер юк. Беренчедән, бу төшенчә үзе берничә мәгънәне аңлата; икенчедән, тәрбия эше формалары төрлечә классификацияләнә. «Педагогика» журналында бу классификациянең нигезләре турында озакка сузылган бәхәсләр барган иде, әмма барыбер нинди дә булса нәтиҗәгә киленмәде.

С.И. Ожегов сүзлегендә «форма» сүзенең 9 мәгънәсе бирелә. Тәрбия эшенең формасы турында сүз барганда, педагоглар һәм укучыларның билгеле бер мөнәсәбәтләр структурасы аша бу эшнең эшчәнлеге чагылышын күздә тоталар. Кайбер педагог-галимнәр тәрбия эшенең формасын – тәрбия процессында катнашучыларның бергәләп эшләү процедурасын һәм конкрет ситуацияләрне оештыруның алдан уйланган тәртибе; тәрбия эшенең тышкы чагылышын тәэмин итүче оештыру алымнары һәм тәрбия чаралары җыелмасы дип билгели. Барлык бу эшгамәлләр аерым педагогик мәсьәләләрне (тәрбия һәм гамәли оештыру) хәл итүгә юнәлтелергә тиеш.

«Тәрбия эшенең формасы» төшенчәсенең мәгънәсен аңлау өчен, бу феноменның педагогик процесста нинди урын алып торуын һәм аның нинди функцияләрне үтәвен билгеләү дөрес булыр.

Беренче функциясе – *җитәкчелек эшен оештыру.* Тәрбия эшенең теләсә кайсы формасы – җитәкчелек мәсьәләсен хәл итүне күздә тота. Җитәкче-оештыручы ролен педагог та, укучылар да үти ала. Эшне оештыру эш-гамәлләрнең билгеле бер логикасын, катнашучыларның бер-берсе белән аралашуын чагылдыра. Тәрбия эшенең хәзерге вакытта традициягә кергән һәм бик күп педагоглар трафыннан кулланыла торган төрле формаларын (әңгәмә, күмәк иҗади эш, конкурслар, сәхнәләштерүләр һ.б.) оештыруның гомуми методлары (алгоритмнары) бар. Бу методлар җитәкчелек итү-оештыру эшчәнлегенең эзлекле рәвештә берничә стадия узуын билгелиләр. Безнең фикеребезчә, педагогик форма – педагогик процессны аның барлык компонентлары бергәлегендә оештырып бетерү ул.

Форманың икенче функциясе – *көйләү.* Теге яки бу форманы куллану педагог белән укучылар арасындагы мөнәсәбәтләрне дә, укучылар арасындагыларны да көйли. Укучы балалар төркемнәрен бергә туплау процессына төрле формалар төрлечә тәэсир итә. Бергәләп эшләү зарурлыгына басым ясалган формалар аркасында социаль мөнәсәбәтләр нормалары формалаша.

Учебное издание

**ХУЗИАХМЕТОВ АНВАР НУРИАХМЕТОВИЧ**
**ЯРУЛЛИН ИЛЬНАР ФАГИМОВИЧ**

**КУРС ЛЕКЦИЙ ПО ТЕОРИИ ВОСПИТАНИЯ**

Учебник для высших и средних педагогических учебных заведений

*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**ХУҖИӘХМӘТОВ ӘНВӘР НУРИӘХМӘТОВИЧ**
**ЯРУЛЛИН ИЛНАР ФӘҺИМОВИЧ**

**ТӘРБИЯ ТӘГЪЛИМАТЫ БУЕНЧА**
**ЛЕКЦИЯЛӘР КУРСЫ**

Югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку әсбабы

Редакторы *Р.Р. Насыйбуллов*
Корректоры *И.Җ. Вәлиев*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.01.2016.
Форматы 60x90$^{1/16}$. Офсет кәгазе. Офсет басма. Басма табагы 64,0.
Тиражы 1400 д. Заказ №396/з

---

«Мәктәп» Татарча Республика нәшрияты.
420111. Казан, Сул Болак урамы, 24.